**СЛАЙД-1**

Буа шәһәре Мулланур Вахитов исемендәге гимназия директоры Зиннатуллин Линар Бәдретдин улы чыгышы.

**Шәһәр мәктәбе шартларында сыйныфтан тыш эшчәнлектәге тәрбия юнәлешләре.Тәҗрибә һәм перспективалар.**

**СЛАЙД-2-4 Кереш**

Бу дөньяның төсен, ямен, зәүкын
Кем аркылы, ничек белдем мин?
Бишектән үк мине өйрәтүчем,
Туган телем – бәгърем, син ул, син!

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, тәрбиячем!
Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсен
Син аңлаттың миңа, укытучым,
Син өйрәттең миңа һәммәсен**. (Х. Туфан)**

Исәнмесез, Ранис Рафисович, мәгариф буенча Совет вәкилләре һәм коллегалар. Сезне Буа шәһәре Мулланур Вахитов исемендәге гимназиянең сыйныфтан тыш эшчәнлектәге тәрбия юнәлешләре буенча эшләү тәҗрибәсе һәм киләчәккә перспективалары белән таныштырырга рөхсәт итегез.

Милли тәрбия шәһәр шартларында шактый четерекле мәсьәләгәгә әйләнде.

Шәһәрдә «бу ярый», «бу ярамый» дигәнне белмәгән тулы бер буын үсеп килә һәм туга ук кулларына төрле гаджетларны тоткан, шуларны карамыйча ашарга да утырмаган үзсүзле, кире «балалар партиясе» барлыкка килде.Аларны ничек итеп милләтебезнең киләчәге итеп тәрбияләргә.

Ләкин мин сезнең алда шатланып әйтә алам,беренче сыйныфка килгәндә бер сүз дә татарча белмәгән балаларыбыз гимназияне бетергәндә татар телендә иркен аралашучан,халкыбызның гореф-гадәтләрен ихтирам итүче егетләр һәм кызлар булып үсеп җитәләр. Без моңа ничек ирешәбез соң?. Мулланур Вахитов исемендәге гимназиядә милли тирәлек-мохит булдырылган. Бездә тәрбия эшчәнлегенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора: үз халкына, теленә, тарихына һәм мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү,үз фикерләрен ана телендә әйтә һәм аралаша белү, балаларда әхлаклылык сыйфатлары һәм гражданлык позициясе булдыру.

**СЛАЙД- 4 (Гаиләләр белән эш)**

Педагог-галим В.Казыйхановның сүзләрен искә төшерик: “Әгәр укытучы-тәрбияче белән бала өчпочмакның ике ягын тәшкил итсә, өченче – таянып торган ягы — ата-ана”.

Әлбәттә, балаларның ирешкән уңышларына, тәрбиялелегенә гимназия коллективы белән ата-аналарның бердәм эшләве саллы йогынты ясый.

Гимназия тормышында ата-аналарның роле зур. Укыту-тәрбия процессында бер генә чара да алардан башка үтми, проблемалар уртага салып хәл ителә.

**СЛАЙД- 5 (Эстетик тәрбия: халкыбыз уеннары, йолалары һәм бәйрәмнәре)**

Халкыбызның буыннан-буынга килгән иҗаты балага гаҗәеп бай рухи азык бирә. Балачак чоры – ул кабатланмас, тылсымлы чор.
Без гимназиябездә халык йолаларына, традицияләренә, иҗатына, гореф-гадәтләренә, сәнгатенә таянып балаларда халкыбызга хас милли үзенчәлекләрне: кунакчыллык, сабырлык, шаянлык тәрбияләргә тырышабыз.

**СЛАЙД- 6-7 (Эстетик тәрбия: Гимназиядә ансамбльләр һәм театраль группалар, смотр һәм конкурсларда катнашу)**

Татар гимназиясе оешуның беренче елларыннан хәзергәчә бездә бик күркәм традиция яшәп килә. Бу – балаларга милли эстетик тәрбия бирү. Башлангыч сыйныф укучыларына милли биюләр ошый ,алар өчен хореография залыбыз бар, өлкән сыйныфтагылар театраль осталык дәресләрендә сәхнә серләрен үзләштерә,аларның уңышлары зур:Буа драма һәм сатира театры оештырган “Ният” конкурсларында Гран-при кадәр оттылар.Ленар Салихов җитәкчелегендә гимназиядә эшләп килүче җыр ансамбле соңгы елларда зур уңышларга ирешеп килә. Укучыларыбыз Бөтендөнья “Җәлил уку”ларында ,”Нәүрүз гүзәле” бәйгесендә дә уңышлы чыгыш ясыйлар.

**СЛАЙД- 8( Әхлакый-патриотик тәрбия)**

Борынгы фәлсәфәчеләр: "Кеше ике тапкыр туа. Беренче тапкыр физик яктан, икенче тапкыр рухи яктан", – дигән. Икенче тапкыр туу иң катлаулы, дәвамлы процесс . Шуңа да гимназиядә алып барылган тәрбиянең бурычы – милли рухтагы әхлаклы балалар тәрбияләү. Гимназиядә укучыларда патриотик аң формалаштыру үзеңнән үзе генә түгел, эзлекле алып барыла Бу эштә бигрәктә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәсхүдә Мәсхүтовна Юнусова җитәкләгән музейның роле зур. Укучыларыбыз аның җитәкчелегендә , бик теләп, туган як тарихын өйрәнә, музей эше буенча сыйныфтан тыш чараларда катнаша.Район һәм Республика вакытлы матбугатында аларның мәкаләләре чыга. Балалар әле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рузинә Һадиевна Низамиева җитәкчелегендә “ Гимназия сулышы” газетасын нәшер итәләр.

**СЛАЙД- 9(Милли үзаң үсеше)**

Укучыларыбызда милли сыйфатлар формалаштыру – тәрбия бирүнең иң әһәмиятле өлеше дип саныйм.Беренчесе- үзеңне милләт вәкиле итеп тану. Бу катлаулы психологик тойгыны формалаштыру милли узаңны тәрбияләүгә бәйле. Милли узаң милли культураның эчтәлеген белүгә һәм аңлауга нигезләнә,ул бездә башлангыч сыйныфтан укуны тәмамланганга кадәр дәвам итә.Бу эштә безгә 2016 нче елның 5 маенда ачылган “Сәләт” клубы зур ярдәм итә. Әнисе Вахитов мәктәбендә белем алган “Сәләт” проекты җитәкчесе Җәүдәт Сөләйманов белән 2019 нчы елда икебез имзалаган килешү нигезендә клубның эшчәнлеге тагы да җанланды. “Сәмрүх” ел премиясе кысаларында "Ел клубы" номинациясендә лауреат булдылар."Сәләт" клубы лидеры Шарипова Рената "Ел сәлкеше" номинациясендә шулай ук лауреат булды..
Милләт тойгысы һәм милли горурлык хисе да бик мөһим. Гимназиядә халкыбызның һәм уку йортыбызның хөрмәткә лаеклы шәхесләре белән очрашулар балаларыбызга зур йогынты ясый. Әле күптән түгел генә булып узган Мультифест бәйгесендә гимназиябезнең 9 нчы сыйныфы укучысы Залялова Әминә халкыбызның “Сак-Сок” бәетенә нигезләнеп эшләгән мультфильмы белән 1 урынга чыкты.

**СЛАЙД- 9( Хезмәт тәрбиясе)**

Татар халкының төп халәте – хезмәт итеп яшәү. Хезмәт искиткеч куәтле тәрбия көченә ия.Балаларыбыз үз юлларын тапсын һәм тиешле дәрәҗәдә эшли алсын өчен гимназия укытучылары һәр гаилә белән тыгыз элемтәдә тора. Болардан тыш, төрле һөнәргә ия булган әтиләр һәм әниләр үзләре хезмәт куйган профессия үзенчәлекләре турында әңгәмәләр оештырып, балаларга һөнәр сайлауда ярдәм күрсәтәләр.Бу юнәлеш буенча хезмәт өйрәтү укытучылары Рифкать Хәсән улы Галятдинов,Мөдәрис кызы Резеда Гадиева зур эш башкаралар. Ир-егетләр белән берлектә ясалган төрле экиятләр геройлары яңа ел алдыннан гимназия каршын бизәп, җюри тарафыннан югары бәя алды. Р.Мударисовна оештырган “Умырзая” түгәрәгенә йөрүче 5 нче сыйныф укучылары район һәм республика конкурсларында призлы урыннар яуладылар.

**СЛАЙД- 9-10 Йомгаклау**

Чыгышымны тәмамлап, шуны әйтәсем килә: гимназиянең бүгенге яшәеше, гамәле бары бер генә максатка – милли телебезне,аның гореф-гадәтләрен саклау, үстерүгә юнәлтелгән.
Гимназиябез зур вакыйганы каршыларга әзерләнә, тарихын барлый.2022 елда гимназиягә 100 яшь тула.Юбилейга багышланып китап әзерләнә.М.М.Вахитов исемендәге мәктәп һәм гимназия белән бәйле һәркемне истәлекләре белән уртаклашырга чакырабыз.
Сезгә беркайчан да кайсы милләттән булуыгызны,туган тамырларыгызны,Буа төбәгеннән чыкканыгызны онытмавыгызны телим.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.